Татарстан Республикасы
Әлки муниципаль районы
Иске Алпар авыл Советы
КАРАРЫ.

2018 нче елның 19 нчы ноябреннән 31№

Җирле референдум нәтиҗәләре турында

Федераль законның “Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 70 статьясы, Федераль законның “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 22 статьясы нигезендә һәм 2018 елның 18 ноябрендә узган референдумда тавыш бирү йомгаклары турында участок сайлау комиссияләре беркетмәләре нигезендә, түбәндәге сораулар каралды:

Җирле референдумга чыгарыла торган:
Сез яшәү урыны буенча Иске Алпар авыл җирлеге территориясендә теркәлгән балигъ булган, ләкин 1 нче группа инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарыннан, биш һәм аннан күбрәк балигъ булмаган балалары булган күпбалалы гаиләләрдән, көндезге формада белем алучы студентлардан һәм 80 яшькә җиткән кешеләрдән тыш, 2019 елда һәр кешедән 600 сум үзара салым алыну һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган салым акчаларын түбәндәге эшләрне үтәү өчен куллану белән килешәсезме:
-урам утларын урнаштыруга материал сатып алуга, яктырту җиһазларын урнаштыруга һәм хезмәт күрсәтү һәм урам утлары куллана торган электр энергиясе өчен түләүгә -75 сум;
- су белән тәэмин итүнең урам системасын төзү, реконструкцияләү һәм ремонтлау, проект-смета эшләре башкару, ремонт, буяу, су башняларын коймалап алу, ярымборылышлы кран сатып алу, гидрантлар урнаштыру, су алу скважинасын тоту, суны анализлаган өчен түләү, су башнясы кулланган электр энергиясе өчен түләү -100 сум;
- җирлек эчендәге юлларны төзекләндерү, карап тоту һәм ремонтлау, юлларны ремонтлау өчен кирәкле материаллар сатып алу һәм урамнарны кышкы чорда кардан чистарту-200 сум;
– төзелеш, кирәкле инвентарь сатып алу, балалар мәйданчыгын төзекләндерү һәм яшелләндерү-175 сум;
- чүп-чар өчен контейнер мәйданчыкларын төзекләндерү, контейнерлар сатып алу һәм ККК чүплекләрен чистарту (белгеч эше өчен түләү)-50сум сорауларын расларга.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча Иске Алпар авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Алпар авыл җирлеге территориясендә җирле референдумны узган дип, ә референдум нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Алпар авыл җирлеге референдумының тавыш бирү нәтиҗәләрен расларга.

3. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Иске Алпар авыл җирлеге чикләрендә урнашкан 18 яшькә җиткән барлык граждannaр, 1 нче группа инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарыннан, биш һәм аннан күбрәк балигъ булмаган балалары булган күпбалалы гаиләләрдән, көндезге формада белем алучы студентлардан һәм 80 яшькә җиткән кешеләрдән тыш, үзара салым акчаларын барлык гражданнар карар чыкканнан соң 12 ай эчендә түләргә.

4. Әлеге карарны Әлки муниципаль районы Иске Алпар авыл җирлеге мәгълүмат стендында бастырып чыгарырга.

Әлки муниципаль районы
Иске Алпар авыл Советы Рәисе,
авыл җирлеге башлыгы Салахов Р.Р.